**№2 (02) октябрь, 2017 ел** 1

**ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК, ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!**

# ХЫЯЛ

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ РАЙОНЫ**
**“ЧАЛМАНАРАТ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ГАЗЕТАСЫ**

## Алтын көз матурлыгы





### Көзге урман

*Көзге урман матур була,*
*Сихри ямьгә төренә.*
*Агачлар да матур булып*
*Алтын төскә күмелә.*

*Алтын яфраклар коела,*
*Җиргә коела тын гына*
*Алтын келәмне хәтерләт*
*Ямь өсти ул тагын да.*

Сәйдәш Шакиров
**VIII класс укучысы**



## Табигатьне саклау – уртак йортыбызны саклау ул.

“Балыкка – су, кошларга – һава, җәнлекләргә - урман, дала, таулар, ә кешегә Туган ил кирәк. Табигатьне саклау - Туган илне саклау ул”, - дигән М.М.Пришвин. Әйе, табигатьне саклау- Туган илне, Туган илне саклау – үзебезне саклау ул.

Табигать кочагы – үзәнлекләр, елга-инешләр, кош-корт, хайваннарның да туган җире. Җирдәге олуг зат – кеше дә үзен табигать баласы, үз анасы дип атый. Димәк, ул табигатьне сакларга, якларга бурычлы.



*Дусларым, кадерлик гел*
*Туган җир табигатен!*
*Каты куллы яман ният*
*Аның нәфислегенә*
*Һичкайчан орынмасын!*

**Сирин Имамов**
**VIII класс укучысы**

## Табигать - йортыбыз.

Табигатебез аллы – гөлле чәчәкләргә күмелеп утыручы болын – кырлары, чишмәләрдән челтерәп аккан саф, чиста сулары, көмештәй саф сулы күлләре, кечкенә генә инештән башлап, зур елгага таба ыргылучы елгачыклары белән бай.

Табигать – ул безне яшәтүче дә, терелтүче дә, дөньяны танырга өйрәтүче дә.

Урман, болын, сулык, күл-ләрне пычратма, чүп ташла-ма, теләсә кайда учак якма!

Агачларны рөхсәтсез кисмә, ботакларын сындырма, үләннәрне тамыры белән йолкыма!

Табигать байлыкларын кирәгеннән артык кулланма!

Аңа зыян салучыларга юл куймыйк һәм үз туган йорты-быз итеп саклыйк, яклыйк һәм матурлыгына, иркен саф һавасына, елга – күлләренә игътибар-сыз калмыйк.

Табигать ул – безне ашата, эчертә, киендерә, сәламәтлекне саклый.

Үзебезнең кылган эшләребез өчен хәзер дә, киләчәк буыннар алдында да җаваплы икәнлегебезне тоеп яшик.



Васил Малик улы Маликов

Танылган рәссам, сынчы, Казандагы М.Вахитов һәм Муса Җәлил һәйкәлләре авторы. “Соңгысы”, “Чекист Голубятников”, “Соңгысы”, “М.Җәлил” дигән скульптуралары өчен 1980 елда ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Актаныш районы Иске Кормаш авылында туган. 1942 нче елда Казанның һөнәрчелек училищесын тәмамлый. ТАССРның халык рәссамы, РСФСРның атказанган рәссамы мактаулы исемнәре бирелә.


**30 октябрь илебездә Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне**

Татар язучылары

Репрессия вакытында кешеләрнең 40%ы- атып үтерелә, 30%ы- лагерьга җибәрелә, 20% - кулаклаштырыла. Бары тик 10%ы гына иректә яши.

СССР да озак елларга сузылган сәяси репрессия нәтиҗәсендә миллионлаган кешегә «кара тамга» тагыла, меңләгән гаепсезләр юк ителә. Кулга алынганнарның күпчелеге зинданнарга ябыла. Магадан, Колыма, НКВД ихатасында, салкын подвалларда, ГУЛАГ лагеренда илебез халкының гомерләре киселә. “Халык дошманы” тамгасы алганнарның туганнары, балалары да түбәнсетүләргә, төрле кыерсытуларга дучар ителә.



**Мәктәбебездә 30 нчы октябрь**

Бу көнне илебездә Сәяси репрессия корбаннарының язмышлары белән тарих укытучысы Айгөл апа Әхмәтхуҗина бик яхшы таныштырды.

Күмәкләшү елларында илебездә үткәрелгән сәяси репрессияләр күпме кешеләрнең гомерләрен өзгән, якыннарын, туганнарын газап утына салган! Биш миллионнан артык кеше яшәгән җирләреннән читкә сөрелгән. 1920 нче еллар азагыннан алып, 1930 нчы еллар башында репрессияләр дулкыны башлана.

Чалманараттан Ширияздан, Хәсән муллалар авылдан чыгарып җибәреләләр. Сталинизм чорында 60 миллионга якын кеше СССРда Сталин һәм аның тарафдарлары алып барган явыз сәясәтнең корбаннары була. Дөньяның әле моңа кадәр дә, моннан соң да бу кадәр вәхшилекне күргәне булмый, чөнки бер сәбәпсезгә, “халык дошманы” дигән шик белән, илнең, төрле милләттләрнең иң көчле шәхесләре, акыл ияләре, зыялылары, үз фикерле кешеләре юк ителә, гади халык та шушы канлы тегермәнгә салып тартыла.

**Лилия Сәрвәрова.**

## Өлкәннәр көне

Өлкәннәр!.. Олы кешеләр!.. Күпме мәгънә табып була бу сүзләрдән. Элек-электән үк олы кешеләр тормышның, яшәешнең нигезен тәшкил иткәннәр: намуслы балалар үстерү, аларның бәхете өчен көрәшү, туган илне дошманнардан азат итү, киләчәгебез якты һәм тыныч булсын өчен, табыннарыбыз мул, көннәребез уң булсын өчен башкарган барлык эшләр дә алар кулы аша үткән.

Хөрмәтле өлкәннәребез! Бетмәс-төкәнмәс жылылык Сездә. Кулларыгыздагы жылылыкны да сизәсебез килә. Кочагыгызда иркәләнәсебез, башыбыздан, иңнәребездән сыйпаганыгызны тоясыбыз килә. Никадәр олуглык, никадәр сабырлык Сездә. Дистә еллар буена жыйналып килгән ул. Тормыштагы үз жиңүләрегез, үз хаталарыгыз хакына тупланган. Ул олуглыкның азы гына бездә булса икән.

Сезгә саулык, сәламәтлек, шатлык-куанычлар, олыгайган көнегездә тыныч тормыш телибез.

Телибез сезгә яшел жәйләр,
Ап-ак карлы кышлар.
Кышларда да, жәйләрдә дә
Бәхетле минутлар.

Ак төннәр телибез сезгә,
Матур тыныч төннәр.
Тагынниләр телик сезгә
Безнең Өлкәннәр

## Һөнәри бәйрәмегез белән!



Сезнең тормыш юлы матур тарих,
Күпләр өчен үрнәк булырлык.
Рәхмәт, дибез, сезгә чын йөрәктән,
Сезнең гомер — безнең горурлык.

VI – VIII класс укучылары тарафыннан укытучыларның һөнәри бәйрәмнәренә багышланган кичә уздырдылар.

## Уңыш бәйрәме

Мәктәбебездә уздырылган бәйрәмдә актив катнаштык. Төрле конкурсларда көч сынаштык. Ярыш төрләре жырлар, уеннар белән үрелеп барды. Бакчада яхшы эшләүче укучылар билгеләнде.

Командаларга “Мактау кәгазе” тапшырылды.



## Өлкәннәргә ярдәм





## *Мәктәбебез укучылары яулаган урләр.*





**Бөтенрәсәй сочинениеләр конкурсының район этабында катнашып, 7 нче класс укучысы И.В.Имамов I урын алды.**
**Аны җиңүе белән котлыйбыз!**
**Укытучысы: Р.С.Галимҗанова**

**Республикакүләм "Киләчәккә билет" иҗади конкурсның район этабында катнашып, 8 нче класс укучысы С.В.Имамов I урын алды.**
**Аны җиңүе белән котлыйбыз!**
**Укытучысы: Ә.Р.Исрафилова.**



**Республикакүләм "Коррупциягә каршы" иҗади конкурсның район этабында катнашып, 8 нче класс укучысы Ф.Д.Гәрәев I урын алды.**
**Аны җиңүе белән котлыйбыз!**
**Укытучысы: Ә.Р.Исрафилова.**

### Көзге уңыш.

Быел яңгырлы булды,
Яшелчәләр дә унды.
Бәрәңге, кишер белән
Бөтен базыбыз тулды.

Алма, чия, сливалар
Балдай татлы булдылар
Әни, җиңги, апалар
Тәмле компот яптылар.

Авылдагы балалар Эшләп үсәләр алар
Көзге уңыш җыйгганда, Катнашалар бит алар да.

**А.А.Хәбирова 5 нче класс укучысы**

**30 октябрь илебездә Сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Россия тарихында җан өшетерлек вакыйга булып уелып калган репрессия еллары әле бүген дә күпләрнең күңелендә саклана.** Сталин режимы милли интеллигенциянең каймагын, күренекле вәкилләрен, ”халык дошманы” буларак, кулга алган. Тикшерү һәм хөкем карары чыгару өчен һәр республикада, һәр өлкәдә өч кешедән торган махсус “өчлекләр” булдырылган. Репрессия корбанына әйләнгән шәхес “үзенең гаебен танып”, гаепләү актына имза куярга мәҗбүр булган. Болар арасында күренекле татар язучылары: **Г.Ибраһимов, К.Тинчурин, М.Галәү, Ф.Кәримнәр** дә бар. Кырык үлемне җиңеп, исән – сау килеш туган илләренә әйләнеп кайтучылар арасында **А.Гыйләҗев, Х.Туфан, И.Салаховлар** да бар.Шул чорда 40 язучының гомере вакытсыз өзелгән!

## Ял сәгатендә

**“Кар” сүзе кергән биш сүз төзи аласызмы?**

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| к | а | р | | | |
| | к | а | р | | |
| | | к | а | р | |
| | | | к | а | р |
| к | а | р | | | |

# Афәрин, Гөлсинә Мөдәрис кызы!






Гөлсинә Мөдәрис кызы Сәетова район мәгариф бүлегенең “Мактау кәгазе” белән бүләкләнде.

Киләчәктә дә эшегездә зур уңышлар, сәламәтлек, озын гомер, бәхет телибез!

Укытучылар һәм укучылар коллективы.

«Хыял» Чалманарат төп гомуми белем бирү укучыларының фәнни-популяр, әдәби-нәфис айлык басмасы
Шеф-мөхәррир: Диана Акбулатова Җаваплы сәркатип: Миләүшә Фазлыева Фотохәбәрче: Сәйдәш Шакиров
Безнең адрес: 423752, Чалманарат авылы, Мәктәп ур., 7 нче йорт. E-mail: Schal.Akt@edu.tatar.ru, chalm.akt@yandex.ru Тираж: 15 данә Кул куелды: 08.00; 28.10.2017